МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.05.2023 Казан ш. № 340-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләр кертү турында

Законнардагы үзгәрешләргә бәйле боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына кертелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
22.05.2023 № 340-пр
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен билгеле бер җир категориясенә кертү яисә җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 27.07.2022 № 469-пр боерыгы белән расланган Җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен билгеле бер җир категориясенә кертү яисә җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бирүчеләр булып физик затлар, шу исәптән, шәхси эшкуарлар, юридик затлар санала.

Гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән затлар тәкъдим итә ала.»;

1.4 пунктта «хезмәт күрсәткәндә» сүзләрен «хезмәт күрсәтү» сүзләре белән алмаштырырга;

2 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6, 2.3.7 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.3.6. Җирләрне яки әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү турында ТР МК карары (җирләрне яки әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерүдән баш тарту турында карар) реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (карарны электрон имза белән имзалаганда).

2.3.7. Үтенечнамәне һәм аңа беркетелгән документларны караудан баш тарту турында хат реквизитлары:

хатның номеры һәм датасы;

үтенечнамәне карарга вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

үтенечнәмәне караудан баш тарту турындагы хатны имзаларга вәкаләтле затның (алга таба - вәкаләтле зат) вазифасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (үтенечнамәне караудан баш тарту турындагы хатны имзалаганда).»;

2.4.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга:

«үтенечнәмәне һәм документларны Министрлыкта регистрацияләгән көннән»;

2.4.3 пунктта «Министрлыкта» сүзен «МФЦ» сүзе белән алыштырырга;

Түбәндәге эчтәлекле 2.4.4, 2.4.5 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.4.4. Үтенеч язуын караудан баш тарту гариза бирүчегә үтенечнәмәне һәм документларны Министрлыкта регистрацияләгән көннән соң 1 эш көне эчендә җибәрелә.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче сайлаган ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.»;

2.11.3 пунктта «җибәрелгән» сүзен «алынган» сүзе белән алыштырырга;

2.14.6 пунктта:

Икенче абзацта «билгеләнгән» сүзе алдыннан «Министрлык» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Алдан язылмау гариза бирүчегә чират тәртибенә мөрәҗәгать итергә каршылык тудырмый.»;

3 бүлектә:

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

1) гариза бирүчегә консультация, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

2) гариза бирүче тапшырган документлар комплектын кабул итү һәм карап чыгу;

3) үтенеч язуы беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген каарп чыгу;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау

5) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү (җирләрне яки әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү турында ТР МК карары проекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында ТР МК карары проектын әзерләү);

7) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру;

8) дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе булган документларда киткән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү.»;

3.5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.»;

3.6.1 пунктның икенче абзацында «2.6.2 пунктта» «2.6.1, 2.6.2 пунктларда» сүзләре белән алыштырырга;

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Бүлек белгече үтенеч язуы Бердәм портал, Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә, гариза бирүчегә үтенеч язуының килүе турында электрон хәбәр юллый.

Үтенеч язуы керүе турында электрон хәбәр һәм үтенеч язуының регистрацияләнүе турында белдерү Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.»;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат һәм логик яктан тикшерү гариза бирүче запросның электрон формасындагы һәр юлны тутырганнан соң Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал запросның электрон формасындагы юлының дөрес тутырылмавын ачыкласа, гариза бирүчегә запросның электрон формасы өстендә үк мәгълүмати хәбәр буларак, ачыкланган ялгыш һәм аны төзәтү тәртибе турында белдерелә.»;

3.6.2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.3. Бүлек белгече Бердәм портал, Республика порталыннан килгән электрон үтенеч язуларның барлыгын тикшерә, көнгә ике тапкырдан да ким

булмаган вакытта кергән гаризаларны һәм беркетелгән документларның электрон образларын (документларны) карап чыга.

Эш номенклатурасына туры китереп үтенеч язуына номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелү Республика порталының шәхси кабинетында автомат рәвештә чагыла.

Бүлек белгече карау өчен документлар кергәч:

электрон формада кергән эшләрне, шул исәптән гариза бирүче беркеткән электрон рәвешле документларны һәм документларның электрон образларын карап чыга;

документларның электрон образларының комплектлылыгын, укылышын тикшерә;

Бердәм порталга, Республика порталына мөрәҗәгать итеп электрон имзаның гамәлдә булу шартларының саклануын тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган документларның электрон образлары бирелгән очракта).

Бүлек белгече үтенеч язуына беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карап, үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Бүлек белгече “Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомоствоара запрослар формалаштыру һәм юллау” административ процедурасын башкаруга күчә».

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта сәбәпләрен күрсәтеп үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат проектын электрон рәвештә әзерли, аны Бүлек мөдире, җир ресурслары идарәсе башлыгы Хокук идарәсе башлыгы белән килештерә, үтенеч язуын караудан баш тарту турында хатка министрның беренче урынбасары кул куюын һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Эш башкару буенча инструкциядә билгеләнгән тәртиптә гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә

Министрның беренче урынбасары электрон документ формасындагы үтенеч язуын караудан баш тарту турындагы хатны электрон имза белән имзалый.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшергәндә аның гамәлдә булу шартлары үтәлмәве ачыкланса, үтенеч язуын караудан баш тарту турындагы хат № 63-ФЗ Федераль законның 11 статьясы пунктларын үз эченә алырга тиеш.

Әлеге Регламентның 3.6.2.3 пункты белән билгеләнгән процедуралар, үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 3.6.2.1 пункты

белән каралган нигезләр булмаса, үтенеч язуы һәм документлар регистрацияләнгән бер эш көне эчендә башкарыла.

Әлеге Регламентның 3.6.2.3 пункты белән билгеләнгән процедуралар, үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 3.6.2.1 пункты белән каралган нигезләр булса, Министрлыкка үтенеч язуы һәм документлар кергән 17 эш көне эчендә башкарыла.

Әлеге Регламентның 3.6.2.3 пункты белән билгеләнгән процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат.»;

3.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.3. Министрлыкка документарь формада гариза бирүчедән кергән документлар комплектын карап чыгу.

Контроль бүлеге хезмәткәре Бүлек белгече катнашында гаризаны һәм беркетелгән документларны карап чыга, үтенеч язуыан һәм беркетелгән документларны регистрацияли һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Гариза бирүче документларның расланмаган күчермәләрен тапшырган очракта, Бүлек белгече оригиналга карап документларның күчермәләрен чагыштыра һәм үз имзасы беләнраслый.

Бүлек белгече үтенеч язуына беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карап, үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Бүлек белгече үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаса, “Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга (оешмаларга) юллау” административ процедурасын башкаруга күчә».

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта сәбәпләрен күрсәтеп үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат проекты әзерли, аны Бүлек мөдире, җир ресурслары идарәсе башлыгы Хокук идарәсе башлыгы белән килештерә, үтенеч язуын караудан баш тарту турында хатка министрның беренче урынбасары кул куюын һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Эш башкару буенча инструкциядә билгеләнгән тәртиптә гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә.

Әлеге Регламентның 3.6.3 пункты белән билгеләнгән процедуралар, үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 3.6.2.1 пункты белән каралган нигезләр булмаса, үтенеч язуы һәм документлар регистрацияләнгән бер эш көне эчендә башкарыла.

Әлеге Регламентның 3.6.3 пункты белән билгеләнгән процедуралар, үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 3.6.2.1 пункты

белән каралган нигезләр булса, Министрлыкка үтенеч язуы һәм документлар кергән 10 эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат.»;

3.6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.4. Документлар Министрлыкка почта аша документарь формада кергән очракта контроль бүлеге хезмәткәре үтенеч язуын һәм документларны карап чыга, регистрацияли һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Бүлек белгече үтенеч язуына беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлегенншн чыгып үтенеч язуын караудан баш тартырга китерә алган әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, Бүлек белгече “Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау” административ процедурасын башкаруга күчә».

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.8.2.1 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта сәбәпләрен күрсәтеп үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат проекты әзерли, аны Бүлек мөдире, җир ресурслары идарәсе башлыгы Хокук идарәсе башлыгы белән килештерә, үтенеч язуын караудан баш тарту турында хатка министрның беренче урынбасары кул куюын һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Эш башкару буенча инструкциядә билгеләнгән тәртиптә гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә.

Әлеге Регламентның 3.6.4 пункты белән билгеләнгән процедуралар, үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2.1 пункты белән каралган нигезләр булмаса, үтенеч язуы һәм документлар регистрацияләнгән бер эш көне эчендә башкарыла.

Әлеге Регламентның 3.6.4 пункты белән билгеләнгән процедуралар, үтенеч язуын караудан баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8.2.1 пункты белән каралган нигезләр булса, Министрлыкка үтенеч язуы һәм документлар кергән 17 эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки үтенеч язуын караудан баш тарту турында хат.»;

3.7, 3.7.1, 3.7.2, 3.7.3, 3.7.4 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау;

3.7.1. Запрос җибәрү өчен нигез булып гариза бирүченең регистрацияләнгән үтенеч язуы тора.

3.7.2. Дәүләт хезмәтен туктатып тору турында нигезләр булмаса, Бүлек белгече контроль бүлегеннән үтенеч язуын һәм документларны алгач, “Үтенеч язуының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыганнан үтү битен” (әлеге Регламентка 2 нче кушымта) тутыра һәм ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада (техник мөмкинлек булмаса – башка ысуллар белән) әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында запрослар юллый.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен соралган документлар исемлеге:

1) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу бите. Запрос ТР буенча ФСХИга юллана;

2) гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында ЕГРИПтан өземтә яки Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрының язу бите. Запрос ТР буенча ФСХИга юллана;

3) җир кишәрлеге турында ЕГРН өземтә яки җир кишәрлеге турында ЕГРНда соралган белешмәнең булмавы турында белдерү кәгазе. Запрос “ТР ФКП” ФБУга юллана;

4) федераль законнарда каралган очракта, дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе. Запрос Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына юллана;

5) җирләр яки җир кишәрлекләрен соралган максатчан кулланының расланган территориаль планлаштыру документларына һәм территориянең планировкасы буенча документациясенә туры килүен раслаган белешмә. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм коммуналь хуҗалык министрлыгына һәм күчерү күздә тотылган җир кишәрлеге урнашкан территория муниципаль берәмлегенең вәкаләтле җирле үзидарә органына юллана.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар күрсәтелгән органнарга гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар гариза һәм документлар регистрацияләнгән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар

3.7.3. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе

субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.

3.7.4. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның $7^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе). Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең соралган документларны (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәрне алуы.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.

Министрлыкның структур бүлекчәләре арасында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм Министрлык карамагында булган мәгълүматны алмашу, шул исәптән, электрон формада, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында Эш башкару буенча инструкция нигезендә алып барыла.»;

3.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында (хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү»;

3.9.2, 3.9.3 пунктларны көчен югалткан дип таныргa;

3.9.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.4. Җирләрне яки әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү турында ТР МК карары проекты яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында ТР МК карары проектын әзерләү (алга таба – ТР МК карары проекты)»;

3.9.4.1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгели торган процедуралар бу Регламентның 2.6.6 пункты нигезендә юлланган запросларга җавап алынганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.»;

3.9.4.3 пунктның икенче абзацында «алдагы процедура» сүзләрен «әлеге Регламентның 3.9.4.1 пункты белән каралган процедуралар» сүзләре белән алмаштырырга;

3.9.4.8 пунктның икенче абзацында «алдагы процедура» сүзләрен «әлеге Регламентның 3.9.4.6 пункты белән каралган процедуралар» сүзләре белән алмаштырырга;

3.9.4.13 пунктны «башкару» сүзеннән соң «аерым» сүзе белән тулыландырырга;

3.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ТР МК карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карап чыга һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен җирләрне яки әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү турында ТР МК карары күчермәсенең яисә җирләрне яки әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү баш тарту турында ТР МК карарының күчермәсенең электрон образы формасында Министрлыкка юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: җирләрне яки әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү турында ТР МК карары күчермәсенең яисә җирләрне яки әлеге җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү баш тарту турында ТР МК карарының (алга таба – күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсенең электрон образы.»;

3.11.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсенең электрон образы гариза бирүчегә үзе сайланган ысул белән бирелә (җибәрелә):»;

3.11.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11.2. Административ процедураны башлау өчен нигез булып контроль бүлеге белгеченең дәүләт хезмәте нәтиҗәсе күчермәсенең электрон образын (күчерү турында карар яки күчерүдән баш тарту турында карар) алуы тора.»;

3.11.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11.4. Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга Республика порталы ашы мөрәҗәгать итсә, гариза бирүченең шәхси кабинетена Бүлек белгече дәүләт хезмәте нәтиҗәсе күчермәсенең электрон образын юллый.»;

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен билгеле бер җир категориясенә кертү яисә җирләрне яки андый җирләр составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасының
җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре
министрына

Җир кишәрлеген бер категориядән башка категориягә күчерү турында үтенеч язуы

______________________________________________________
(гражданинның фамилиясе, исеме әтисенең исеме яки юридик затның атамасы)
җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүне сорый
______________________________________________________
(җирнең гамәлдә булган категориясе)
кадастр номеры ______________________________________,
______________________________________________ хокукларында
(гамәлдә булган хокук атамасы)
______________________________________________________
(җирне файдаланучы атамасы)
______________________________________________ җир категориясенә
(җир кишәрлеген күчерүне күздә тоткан категория)
______________________________________________________ өчен.
(максатчан билгеләнеш)

Күчерүнең нигезләмәсе: территория планировкасының расланган документына туры килә ______________________________________
(реквизиты территория планировкасы документын раслау турында,
______________________________________________________
территория планировкасының расланган документларына үзгәрешләр кертү турында муниципаль берәмлек советы карары реквизитлары (булса))

| | |
|---|---|
| Гариза бирүченең почта адресы | |
| | |

| | |
|---|---|
| Элемтә өчен телефон | |

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә _______________________________________________________;

(күрсәтелә: электрон документ формасында МФЦга, электрон документ экземплярлары рәвешендә кәгазьдә; Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинетка);

- Министрлыкка бирергә ______________________

_____________________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ формасында, электрон документ формасында яки электрон документ экземплярлары рәвешендә кәгазьдә)

Әлеге үтенеч язуына исемлек буенча документлар беркетелә.

*Раслыйм: үтенеч язуына кертелгән, минем шәхесемә һәм мине тәкъдим иткән затка кагылган, шулай ук астарак мин керткән мәгълүмат дөрес. Үтенеч язуына беркетлгән документлар (документларның скан-күчермәләре) гариза биргән вакыттагы Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гамәлдә һәм дөрес мәгълүмат бирә.*

Гариза бирүченең (бирүчеләрнең), ышанычнамә буенча вәкилнең (вәкилләрнең) имзасы

от «___» ___________ № __________________________________________________

_______________________________________________/_______________________/

(гариха бирүченең (вәкиленең) фамилия, исем, әтисе исеме (булса) (имза)

М.П. <*>

-------------------------------

<*> Россия Федерациясе законнары буенча мөһер булу бурычы куелган очракларда.»;

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 23.05.2022 № 291-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 12.08.2022 № 498-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән):

1.3 пунктта «хезмәт күрсәткәндә» сүзләрен «хезмәт күрсәтү» сүзләре белән алмаштырырга;

2 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6, 2.3.7 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.3.6. Торакны гражданнар милке итеп бирү турында Министрлык карары (торакны гражданнар милке итеп бирүдән баш тарту) реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (торакны гражданнар милке итеп бирү турында карарны (торакны гражданнар милке итеп бирүдән баш тарту) электрон имза белән имзалаганда).

2.3.7. Торакны гражданнар милке итеп бирү шартнамәсе (алга таба - шартнамә) реквизитлары:

Шартнамә төзүгә вәкаләтле орган атамасы;

Шартнамә имзалауга вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (торакны гражданнар милке итеп бирү турында карарны (торакны гражданнар милке итеп бирүдән баш тарту) электрон имза белән имзалаганда).»;

2.4.3 пунктта «Министрлык» сүзен «МФЦ» сүзе белән алыштырырга;

Түбәндәге эчтәлекле 2.4.5, 2.4.6 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.

2.4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче сайлаган ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.»;

2.11.3 пунктта «җибәрелгән» сүзен «алынган» сүзе белән алыштырырга;

2.13.1 пунктның дүртенче абзацын «Министрлык сайтында» сүзләреннән «Бердәм порталда,» сүзләре белән тулыландырырга;

2.13.3 пунктны «шәхси кабинетта» сүзләре алдыннан «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

2.14.6 пунктның беренче абзацын «(алга таба – язылу)» сүзләреннән соң «Бердәм порталда,» сүзләре белән тулыландырырга;

3 бүлектә:

3.4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;»;

3.5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.»;

3.6.1 пунктның икенче абзацында «2.6.2 пунктта» сүзләрен «2.6.1, 2.6.2 пунктларда» сүзләре белән алыштырырга;

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Бүлек белгече гариза Бердәм портал, Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә, гариза бирүчегә гариза килүе турында электрон хәбәр юллый;

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.»;

3.6.2.2 пунктта:

җиденче абзацта «үтенеч язуы» сүзен «гариза» сүзе белән алыштырырга;

унынчы абзацта «үтенеч язуы» сүзен «гариза» сүзе белән алыштырырга;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат һәм логик яктан тикшерү гариза бирүче запросның электрон формасындагы һәр юлны тутырганнан соң Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал запросның электрон формасындагы юлының дөрес тутырылмавын ачыкласа, гариза бирүчегә запросның электрон формасы өстендә үк мәгълүмати хәбәр буларак, ачыкланган ялгыш һәм аны төзәтү тәртибе турында белдерелә.»;

3.6.2.3 пунктта:

беренче абзацны «хезмәткәре» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләре белән тулыландырырга;

алтынчы абзацны «Республика порталы» сүзләре алдыннан «Бердәм портал,» сүзләре белән тулыландырырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрәстеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту хәбәре юллый.»;

тугызынчы, унынчы абзацларны көчен югалткан дип танырга;

3.6.2.4 пунктны «башкару» сүзе алдыннан «аерым процедураларны» сүзләре белән тулыландырырга;

3.6.3 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән баш тарту карары проекты, яки гариза бирүчегә кайтарылган документлар.»;

3.6.4 пунктның алтынчы абзацында «сәбәпләре күрсәтелеп» сүзләрен « документларны кабул итүдән язмача баш тартып» сүзләре белән алыштырырга;

3.7, 3.7.1, 3.7.2, 3.7.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.7.1. Запрос җибәрү өчен нигез булып гариза бирүченең регистрацияләнгән гаризасы тора.

3.7.2. Бүлек белгече контроль бүлегеннән гаризаны һәм документларны алгач әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында запрослар әзерли һәм юллый (шул исәптән, ведомоствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен соралган документлар исемлеге:

1) күчемсез милек объектына төп тасвирламалар һәм теркәлгән хокуклар турында ЕГРН өземтә. Запрос ТР буенча Росреестрга юллана;

2) Аерым затның үзендә булган күчемсез милеккә хокук (хокуклар) турында ЕГРН өземтәсе. Запрос ТР буенча Росреестрга юллана;

3) торакны биләүченең гаиләсендәге 14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган балаларның тууы дәүләти регистрацияләнүе турында белешмә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенә (балигъ булмаган бала 2018 елның 1 октябренә кадәр туса) яки Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсенә (балигъ булмаган була 2018 елның 1 октябреннән соң туса) юллана;

4) опекун, попечитель билгеләнүе турында карар, опекунлык таныклыгы күчермәсе, опекунлык һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләү өчен беренчел рөхсәт - бары тик 14 яше тулмаган балалар, эшчәнлеккә сәләтсез гражданнар яшәгән торак приватизацияләнгәндә. Запрос җирле үзидарәнең вәкаләтле органына юллана;

5) опекунлык һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләү өчен рөхсәте, опекунлык таныклыгы күчермәсе - бары тик 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган балалар яки эшчәнлеккә сәләте чикле гражданнар яшәгән торак приватизацияләнгәндә. Запрос җирле үзидарәнең вәкаләтле органына юллана;

6) торак йортның аңа куелган таләпләргә туры килүе турында «Бинаны торак дип тану, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең № 47 карарына (алга таба - РФ Хөкүмәте карары № 47) туры китерелгән форма буенча ведомоствоара комиссия бәяләмәсе (күпфатирлы йортны эксплуатацияләү өчен рөхсәт бирелгән көннән

соң биш елдан артык вакыт үтмәгән булса). Запрос Татарстан Республикасының вәкаләтле органына юллана.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар күрсәтелгән органнарга гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көнендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар

3.7.3. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.»;

Түбәндәге эчтәлекле 3.7.5 пункт белән тулыландырырга:

«3.7.5. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның $7^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе). Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең соралган документларны (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәрне алуы.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.»;

3.9.10 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9.9 пункт һәм әлеге пункт билгеләгән процедуралар әлеге Регламентның 3.9.7, 3.9.8 пунктлары белән билгеләнгән процедуралар тәмамланган көндә гамәлгә ашырыла.»;

3.10.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе гариза бирүчегә үзе сайланган ысул белән бирелә (җибәрелә):»;

3.12.3 пунктның икенче абзацында «регистрацияләнгәннән соң бер эш көне эчендә» сүзләрен «кергән көндә»сүзләре белән алыштырырга;

3.12.4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе: үзгәрешләр кертеп гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) документ.»;

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Торак фонды белән идарә итү департаменты» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 28.04.2022 № 243-пр боерыгы белән расланган Россия Федерациясе гражданнарына үзләре биләп торган, «Торак фонды белән идарә итү департаменты» дәүләт бюджет учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән торакларны милек итеп тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентында (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 12.08.2022 № 497-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән):

1.3 пунктта «хезмәт күрсәткәндә» сүзләрен «хезмәт күрсәтү» сүзләре белән алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә үзе сайлап алган тапшыру ысулы белән тапшырыла (юллана):

Гариза бирүченең шәхсән үзенә язмача яки почта аша;

«ТФД» ДБУ җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы куелган электрон документ формасында электрон почта адресына һәм (яки) Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы) гариза бирүченең шәхси кабинетына.»;

2.3.3 пунктта «Министрлык» сүзен ««ТФД» ДБУ» сүзләре белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.3.5, 2.3.6, 2.3.7 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.3.5. Әлеге Регламентның 2.3.2 пункутында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гариза бирүче шәхсән үзе «ТФД» ДБУдан алырга хокуклы.

2.3.6. Гражданнарга торакны милек итеп тапшыру турында (гражданнарга торакны милек итеп тапшырудан баш тарту турында) «ТФД» ДБУ» карары реквизитлары:

карарның номеры һәм датасы;

карар кабул итүгә вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

карар кабул итүгә вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (гражданнарга торакны милек итеп тапшыру турында карарны (гражданнарга торакны милек итеп тапшырудан баш тарту турында) электрон имза белән имзалаганда.

2.3.7. Гражданнарга торакны милек итеп тапшыру шартнамәсе (алга таба – шартнамә) реквизитлары:

Шартнамә төзүгә вәкаләтле орган атамасы;

Шартнамә имзалауга вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

гариза бирүченең вәкиленең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса).»;

2.4.1 пунктны «ТФД» ДБУ» сүзләре белән тулыландырырга;

2.4.2 пунктта Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталында (https:// www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал) сүзләрен «Бердәм порталда» сүзләре белән алыштырырга,

2.4.3 пунктта «ТФД» ДБУ» сүзләрен «МФЦ» сүзе белән алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.4, 2.4.5 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче «ТФД» ДБУ»га мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче күрсәткән ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.»;

2.14.6 пунктның беренча абзацын «(алга таба – язылу)» сүзләреннән соң «Бердәм порталда,» сүзләре белән тулыландырырга;

3 бүлектә:

3.4.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;»;

3.5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.»;

3.6.1 пунктның беренче абзацында «2.6.2 пунктта күрсәтелгән» сүзләрен «2.6.1, 2.6.2 пунктларда» сүзләренә алыштырырга;

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. «ТФД» ДБУ» белгече гариза Бердәм портал, Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә.

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Бердәм портал, Республика порталындагы шәхси кабинетта гариза каралу статусында автомат рәвештә чагыла.»;

«3.6.2.2 пунктның унөченче абзацында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат һәм логик яктан тикшерү гариза бирүче запросның электрон формасындагы һәр юлны тутырганнан соң Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал запросның электрон формасындагы юлының дөрес тутырылмавын ачыкласа, гариза бирүчегә запросның электрон формасы өстендә үк мәгълүмати хәбәр буларак, ачыкланган ялгыш һәм аны төзәтү тәртибе турында белдерелә.»;

3.6.2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.3. «ТФД» ДБУ» хезмәткәре Республика порталыннан килгән электрон гаризаларның барлыгын тикшерә, көнгә ике тапкырдан да ким булмаган вакытта кергән гаризаларны һәм беркетелгән документларның электрон образларын (документларны) карап чыга.

Эш номенклатурасына туры китереп гаризага номер һәм «Документларны тикшерү» статусы бирә, Бердәм портал, Республика порталының шәхси кабинетында автомат рәвештә чагыла.

«ТФД» ДБУ» хезмәткәре карау өчен документлар кергәч:

электрон формада кергән эшләрне, шул исәптән гариза бирүче беркеткән электрон рәвешле документларны һәм документларның электрон образларын карап чыга;

документларның электрон образларының комплектлылыгын, укылышын тикшерә;

Бердәм порталга, Республика порталына мөрәҗәгать итеп электрон имзаның гамәлдә булу шартларының саклануын тикшерә (гариза бирүче

тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган документларның электрон образлары бирелгән очракта).

«ТФД» ДБУ» хезмәткәре әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр юллый.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшергәндә аның гамәлдә булу шартлары үтәлмәве ачыкланса, үтенеч язуын караудан баш тарту турындагы хат № 63-ФЗ Федераль законның 11 статьясы пунктларын үз эченә алырга тиеш.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаса, «ТФД» ДБУ» хезмәткәре “Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау” административ процедурасын башкаруга күчә.»;

3.6.3.2 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедуралар башкарылу нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки гариза бирүчегә сәбәбе әйтелеп кайтарылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зариру документлар.»;

3.6.3.3 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедуралар башкаруның нәтиҗәсе: карау өчен кабул ителгән документлар комплекты яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән баш тарту карары проекты, яки гариза бирүчегә кайтарылган документлар.»;

3.7, 3.7.1 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.7.1. «ТФД» ДБУ хезмәткәре гаризаны һәм документларны регистрацияләгәннән соң әлеге Регламентның 2.6.5 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында запрослар әзерли һәм юллый (шул исәптән, ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен соралган документлар исемлеге:

1) күчемсез милек объектының төп тасвирламалары һәм регистрацияләнгән хокуклар турында ЕГРНнан өземтә. ТР буенча Росреестрга юллана;

2) аерым затның үзендә булган күчемсез милеккә хокук (хокуклар) турында ЕГРН өземтәсе. ТР буенча Росреестрга юллана;

3) торакны биләүченең гаиләсендәге 14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган балаларның тууы дәүләти регистрацияләнүе турында белешмә. Запрос Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының гражданлык хәле актларын

теркәү идарәсенә (балигъ булмаган бала 2018 елның 1 октябренә кадәр туса) яки Татарстан Республикасы буенча федераль салым хезмәте идарәсенә (балигъ булмаган була 2018 елның 1 октябреннән соң туса) юллана;

4) опекун, попечитель билгеләнүе турында карар, опекунлык таныклыгы күчермәсе, опекунлык һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләү өчен беренчел рөхсәт - бары тик 14 яше тулмаган балалар, эшчәнлеккә сәләтсез гражданнар яшәгән торак приватизацияләнгәндә. Запрос җирле үзидарәнең вәкаләтле органына юллана;

5) опекунлык һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләү өчен рөхсәте, опекунлык таныклыгы күчермәсе - бары тик 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган балалар яки эшчәнлеккә сәләте чикле гражданнар яшәгән торак приватизацияләнгәндә. Запрос җирле үзидарәнең вәкаләтле органына юллана;

6) торак йортның аңа куелган таләпләргә туры килүе турында «Бинаны торак дип тану, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварендәге № 47 карарына туры китерелгән форма буенча ведомствоара комиссия бәяләмәсе (күпфатирлы йортны эксплуатацияләү өчен рөхсәт бирелгән көннән соң биш елдан артык вакыт үтмәгән булса). Запрос Татарстан Республикасының вәкаләтле органына юллана.

Күпфатирлы торак йортны аварияле дип тану фактының булу/булмавы турында белешмә (күпфатирлы йортны эксплуатацияләү өчен рөхсәт бирелгән көннән соң биш елдан артык вакыт үткән булса) «Реформа ЖКХ» Дәүләт корпорациясенең автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан – торак-коммуналь хуҗалыгын реформалаштыруга ярдәм фондыннан алына.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар белән соралган белешмәләр гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү мөмкинлекләрен дәүләт хезмәте күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актларга туры китереп, төрле яктан карау максатыннан җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедуралар тәмамлангач ун көндә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар.»;

3.7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.7.2. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.5 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати

хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.»;

Түбәндәге эчтәлекле 3.7.4 пункт белән тулыландырырга:

«3.7.4. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның $7^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе). Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең соралган документларны (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәрне алуы.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.»;

3.10.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе гариза бирүчегә үзе сайланган ысул белән бирелә (җибәрелә):»;

3.12.5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе: үзгәрешләр кертеп гариза бирүчегә тапшырылган (юлланган) документ.»;

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гаммәви сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 30.09.2022 № 584-пр боерыгы белән расланган

Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гаммәви сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына:

2 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.8, 2.3.9 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.3.8. Җирләрне яки җир кишәрлеген файдалануга рөхсәт (җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар) реквизитлары:

рөхсәт (карар) номеры һәм датасы;

рөхсәт бирүгә (карар кабул итүгә) вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

рөхсәт бирүгә (карар кабул итүгә) вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (җирләрне яки җир кишәрлеген файдалануга рөхсәт (җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар) электрон имза белән имзалаганда).

2.3.9. Җир кишәрлегендә объект урнаштыру рөхсәте (җир кишәрлегендә объект урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар) реквизитлары:

рөхсәт (карар) номеры һәм датасы;

рөхсәт бирүгә (карар кабул итүгә) вәкаләтле орган атамасы;

гариза бирүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса) (физик зат өчен);

юридик зат атамасы;

рөхсәт бирүгә (карар кабул итүгә) вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (җирләрне яки җир кишәрлеген файдалануга рөхсәт (җир кишәрлеген куллануга рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар) электрон имза белән имзалаганда) электрон имза белән имзалаганда).»;

2.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2. Гариза бирүче гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Бердәм портал, Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинеты (алга таба – шәхси кабинет) аша тапшырса, эш номенклатурасына туры китереп гаризага Бердәм портал, Республика порталының шәхси кабинетында күренеп торган номер һәм «Документларны

тикшерү» статусы бирелгәннән соң дәүләт хезмәте Министрлык тарафыннан 15 эш көне эчендә күрсәтелә.»;

2.4.3 пунктта «Министрлык» сүзен «МФЦ» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.5, 2.4.6 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документлар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.

2.4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче күрсәткән ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.»;

2.11.3 пунктта «җибәрелгән» сүзен «алынган» сүзе белән алыштырырга;

2.13.1 пунктның дүртенче абзацын «Министрлык сайтында» сүзләреннән соң «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

2.13.3 пунктның беренче абзацын «шәхси кабинетта» сүзләреннән соң «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

2.14.4 пунктның җиденче абзацын «тәэмин итүче» сүзләреннән соң «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

2.14.6 пунктның беренче абзацын «тәэмин итүче» сүзләреннән соң «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

3 бүлектә:

3.4 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;»;

3.5.3 пунктта «шулай ук» сүзләреннән соң «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

3.5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.»;

3.6.1 пунктның икенче абзацында «2.6.2 пунктта» сүзләрен «2.6.1, 2.6.2 пунктларда» сүзләренә алыштырырга;

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Бүлек белгече гариза Бердәм портал, Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә, гариза бирүчегә гариза килүе турында электрон хәбәр юллый;

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.»;

3.6.2.3 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, баш тарту сәбәпләрен күрәстеп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту хәбәре юллый.»;

тугызынчы, унынчы абзацларны көчен югалткан дип танырга;

3.6.2.4 пунктны «Башкару» сүзеннән «аерым» сүзе белән тулыландырырга;

3.6.3 пунктта:

җиденче абзацта «3.6.2 пунктта» сүзләрен «3.6.2.3, 3.6.3 пунктларда» сүзләрен алыштырырга;

сигезенче абзацта «дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән баш тарту карары проекты, яки» сүзләрен «дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган документларны кабул итүдән язмача баш тарту,» сүзләренә алыштырырга;

3.6.4 пунктта:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгеләгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

Җиденче абзацта «кайтару сәбәпләрен ачыклап» сүзләрен «документларны кабул итүдән язмача баш тарту» сүзләренә алмаштырырга;

3.8, 3.8.1, 3.8.2, 3.8.3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау»;

3.8.1. Запрос җибәрү өчен нигез булып гариза бирүченең регистрацияләнгән гаризасы тора.»;

3.8.2. Бүлек белгече контроль бүлегеннән гаризаны һәм документларны алгач, “Гаризаның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыганнан үтү битен” (әлеге Регламентка 5 нче кушымта) тутыра һәм запрослар юллый (шул исәптән, ведомоствоара электрон арадашлык системасын кулланып): әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен соралган документлар исемлегенә түбәндәгеләр керә:

1. Җир кишәрлеге турында ЕГРНнан өземтә. Запрос Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юллана.

2. Гариза бирүче булган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә. Запрос Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юллана.

3. Гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында ЕГРИПтан өземтә. Запрос Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юллана.

4. Муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетының объектлар урнаштыруга ризалыгы. Запрос тиешле муниципаль район (шәһәр округы) башкарма комитетына юллана.

5. Җир астын геологик яктан өйрәнү буенча эшләр башкару (андый эшләр үткәрелгәндә) хокукын раслаган лицензия күчермәсе. Запрос федераль вәкаләтле органга юллана.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар күрсәтелгән органнарга гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура гариза һәм документлар регистрацияләнгән көндә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар

3.8.3. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.8.5 пункт белән тулыландырырга:

«3.8.5. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның $7^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе). Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең

соралган документларны (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәрне алуы.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.»;

3.9.8 пунктның икенче абзацында «алдагы процедура беткәндә» сүзләрен «әлеге Регламентның 3.9.5 пункты белән каралган процедуралар» сүзләре белән алыштырырга.

3.9.10 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«3.9.9 пункт белән билгеләнгән процедура әлеге Регламентның 3.9.7, 3.9.8 пунктлары белән каралган процедуралар тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.9.13 пунктны «Башкару» сүзеннән соң «аерым» сүзе белән тулыландырырга;

3.10.1 пунктның беренче абзацында «нәтиҗәсен бирү» сүзләрен «Нәтиҗә» сүзе белән алмаштырырга;

3.12.2 пунктның икенче абзацында «гариза регистрацияләнгән бер эш көнендә» сүзләрен «гариза кергән көнне» сүзләре белән алмаштырырга;

3.12.3 пунктта:

беренче абзац түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12.3. Бүлек белгече документларны карый да, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нштиҗәсегә үзгәрешләр кертү проекты әзерли, әлеге Регламентның 3.9.3 – 3.9.12 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) имза куйдырып шәхсән үзенә төзәтелгән документны тапшыра, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган төп нөсхәне ала, яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта аша) Министрлыкка техник хата булган документның төп нөсхәсен китереп документны алу мөмкинлеге турында хат юллый.»;

өченче абзацны «кертелгән үзгәрешләр белән» сүзләре белән тулыландырырга;

Регламентка 4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итергә:

«Дәүләт милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гаммәви сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына

4 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

____________________________________

(Ф.И.ӘИ.(соңгысы - булса). – физик затлар өчен,

_______________________________________

яшәү урыны

_______________________________________

(гариза бирүченең шәхесен раслаган документ реквизиты)

_______________________________________

урнашу урыны (шәхси эшмәкәрләр өчен)

ГРИП турында белешмә _______________ (шәхси эшмәкәрләр өчен)

_________________________________________

Тулы атамасы, оештыру-хокукый формасы – юридик зат өчен)

__________________________________________

ГРЮЛ турында белешмә _____________________

___________________________________________

(Ф.И. ӘИ(булса) – гариза бирүче вәкиле

____________________________________

(гариза бирүченең шәхесен раслаган документ реквизиты)

_______________________________________

гариза бирүче белән элемтәгә керү өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы

_________________________________

Телефон

Татарстан Республикасы милкендә булган җирләрне яки җир кишәрлеген, җир кишәрлекләрен бирмичә һәм сервитут, гаммәви сервитут урнаштырмыйча кулланырга рөхсәт бирү турында

ГАРИЗА

Татарстан Республикасы милке булган____________________________
__________________________________________________________________

(барлык җир кишәрлеген яки җир кишәрлеге кисәген куллану планлаштырылган очракта)

кадастр номерлы җир кишәрлеген, ________________________________________

(җирләрне куллану планлаштырылганда)

кадастр кварталында урнашкан җирләрне җир кишәрлеген бирмичә һәм сервитутлар урнаштырмыйча кулланырга (объектлар урнаштырырга) рөхсәт бирүегезне сорыйм.

______________________________________________________________

(объект төре)

Объектларның урнашу срогы__________________________________

Россия Федерациясе законнарына туры китереп объектларны урнаштырганда
оборона һәм иминлекне тәэмин итү өчен торак пунктлар җирләре составыннан бирелгән җирләр яки җир кишәрлеге өлешләрендә, промышленность, энергетика, транспорт, элемтә, радио, телевидение, информатика җирләрендә, космик эшчәнлекне тәэмин итү җирләрендә, оборона, иминлек һәм башка махсус билгеләнештәге җирләрдә (Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясының 2 кисәгендәге 3 пунктында күрсәтелгән җирләр искәрмә булып тора) җир кишәрлеге чикләрендә урнашкан агачларны, куакларны кисү __________________________________

(таләп ителә /таләп ителми)

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен:

- җибәрергә _______________________________________________________;

(күрсәтелә: МФЦга - электрон документ формасында, электрон документның кәгазьгә төшергән экземплярын; Бердәм порталга, Республика порталында шәхси кабинетка);

- Министрлыкта бирергә ___________________

________________________________________________________.

(күрсәтелә: кәгазь документ, электрон документ формасында яки электрон документның кәгазьгә төшерелгән экземпляры)

*Раслыйм: үтенеч язуына кертелгән минем шәхесемә һәм мин вәкиллек иткән затка кагылышлы мәгълүматлар, шулай ук, мин керткән белешмәләр дөреслеккә туры килә. Үтенеч язуына теркәлгән документлар (документларның скан-күчермәләре) граиза биргән вакыттагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртипләргә туры килә, алар гамәлдә һәм дөрес мәгълүмат бирәләр.*

Гариза бирүче(ләр), «__» __________ № ______________ ышаныч кәгазе буенча вәкил(ләр) имзасы

__________________________________________________/_______________________/

(гариза бирүченең (вәкилнең) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булса) (имза)

М.П. (мөһер булса)

-------------------------------

Гариза кабул ителгән: "___"__________20__ел

_______/____________________/имза, гаризаны кабул итеп алган белгечнең фамилиясе, инициаллары)»;

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы мөлкәт реестрыннан хисап объектлары турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 12.08.2022 № 495-пр боерыгы

белән расланган Татарстан Республикасы мөлкәт реестрыннан хисап объектлары турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Гариза бирүчеләр булып физик затлар, шул исәптән, шәхси эшкуарлар, юридик затлар санала»;

1.3 пунктта «хезмәт күрсәткәндә» сүзләрен «хезмәт күрсәтү» сүзләре белән алмаштырырга;

2 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 2.3.6, 2.3.7, 2.3.8 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.3.6. Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте реестрыннан өземтә (алга таба – өземтә) реквизитлары:

өземтәнең номеры һәм датасы;

өземтә бирергә вәкаләтле орган атамасы;

өземтәне имзаларга вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (өземтәне электрон имза белән имзалаганда).

2.3.7. Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте реестрында мөлкәт объекты булуы (булмавы) турында белешмә (алга таба – белешмә) реквизитлары:

номер һәм дата;

белешмәне имзаларга вәкаләтле орган атамасы;

белешмәне имзаларга вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (белешмәне электрон имза белән имзалаганда).

2.3.8. Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте реестрыннан соралган мәгълүматны бирүдән баш тарту (алга таба – баш тарту) реквизитлары:

номер һәм дата;

баш тартуны имзаларга вәкаләтле орган атамасы;

баш тартуны имзаларга вәкаләтле зат вазифасы (алга таба – вәкаләтле зат);

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (соңгысы - булса);

электрон имза турында белешмә (баш тартуны электрон имза белән имзалаганда).»;

2.4.3 пунктта «Министрлыкта документлар» сүзләрен «МФЦда документлар» сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.4, 2.4.5 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документлар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне тапшырыла.

2.4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документ гариза бирүче сайлаган ысул белән, шул исәптән, электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә.»;

2.11.3 пунктта «җибәрелгән» сүзен «алынган» сүзе белән алыштырырга;

2.13.1 пунктның дүртенче абзацын «Министрлык сайтында» сүзләреннән «Бердәм порталда,» сүзләре белән тулыландырырга;

2.14.4 пунктның җиденче абзацын «тәэмин итүче» сүзләреннән соң «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

2.14.6 пунктның беренче абзацын «(алга таба – язылу)» сүзләреннән соң «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

3 бүлектә:

3.4. пунктның дүртенче абзацын үбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;»;

3.5.3 пунктта «шулай ук,» сүзләреннән соң «Бердәм порталда» сүзләре белән тулыландырырга;

3.5.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә үтәлә.»;

3.6.1 пунктның икенче абзацында «2.6.2 пунктта» сүзләрен «2.6.1, 2.6.2 пунктларда» сүзләре белән алмаштырырга;

3.6.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2.1. Бүлек белгече гариза Бердәм портал, Республика порталы аша бирелгәндә 1 эш көне эчендә, гариза ял яки бәйрәм көнендә керсә – беренче эш көнендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итә, гариза бирүчегә гариза килүе турында электрон хәбәр юллый;

Гариза керүе турында электрон хәбәр һәм гаризаның регистрацияләнүе турында белдерү Республика порталындагы шәхси кабинетта үтенеч язуы каралу статусында автомат рәвештә чагыла.»;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат һәм логик яктан тикшерү гариза бирүче запросның электрон формасындагы һәр юлны тутырганнан соң Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә башкарыла. Бердәм портал запросның электрон формасындагы юлының дөрес тутырылмавын ачыкласа, гариза

бирүчегә запросның электрон формасы өстендә үк мәгълүмати хәбәр буларак, ачыкланган ялгыш һәм аны төзәтү тәртибе турында белдерелә.»;

3.6.4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пункт билгеләгән процедуралар гариза һәм документлар кергән көн эчендә гамәлгә ашырыла.»;

3.7, 3.7.1, 3.7.2, 3.7.3 пунктлары түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.7.1. Запрос җибәрү өчен нигез булып гариза бирүченең регистрацияләнгән гаризасы тора.

3.7.2. Специалист Отдела после получения запроса и документов подготавливает и направляет (в том числе с использованием единой системы межведомственного электронного взаимодействия) запросы: о предоставлении документов и сведений, предусмотренных пунктом 2.6.6 настоящего Регламента.

Бүлек белгече контроль бүлегеннән запросны һәм документларны алгач әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документларны һәм мәгълүматны бирү турында запрослар әзерли һәм юллый (шул исәптән, ведомостводара электрон арадашлык системасы аша электрон формада).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен соралган документлар исемлегенә түбәндәгеләр керә:

1. ЕГРЮЛдан гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу бите. Запрос ТР буенча ФСХИга юллана.

2. ЕГРИПтан гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында өземтә яки шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан язу бите. Запрос ТР буенча ФСХИга юллана.

3. Күчемсез милек турында ЕГРНнан өземтә яки Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында соралган мәгълүматлар булмавы турында белдерү. Запрос ТР буенча Росреестрга юллана.

4. ТР буенча Росреестрдан күчемсез милеккә хокуклар күчү турында ЕГРН өземтәсе. Запрос ТР буенча Росреестрга юллана.

5. Аерым затның аның күчемсез милек объектларына хокуклары теркәлүе турында ЕГРН өземтәсе. Запрос ТР буенча Росреестрга юллана.

Ведомствоара мәгълүмати запрослар күрсәтелгән органнарга гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү максатыннан җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланган көндә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүмат (документлар) бирү турындагы запрослар

3.7.3. Ведомствоара запрослар буенча әлеге Регламентның 2.6.6 пункты белән каралган документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) алар сакланган органнардан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кагыйдәләрен, шул исәптән, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителгән кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” 2021 елның 23 июнендәге № 963 карары нигезендә тиешле запрос җибәрелгәннән соң 48 сәгатьтән дә соңга калмаган вакыт эчендә электрон рәвештә бирелә.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.7.5 пункт блеән тулыландырырга:

«3.7.5. Ведомствоара мәгълүмати запрослар кәгазь рәвештә дә бирелә ала:

1) ведомствоара мәгълүмати запросларда соралган белешмәләр электрон формада булмаса, электрон формада бирелү мөмкин түгел;

2) ведомствоара запрос юллаганда документларның төп нөсхәсенең кәгазьдә бирелү ихтыяҗы булганда. Ведомствоара хезмәттәшлек кәгазьдә бирелсә, әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында күрсәтелгән документларны (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) әлеге документлар үз карамагында булган органнар бирә.

№ 210-ФЗ Федераль законның $7^2$ статьясының 3 кисәге нигезендә ведомствоара запросларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара запрос кергәннән соң биш эш көненнән арта алмый (ике эш көне – дәүләт кадастр учеты һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт регистрациясе). Административ процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченең соралган документларны (күчермәләре яки аларда булган белешмәләр), яки баш тарту турында хәбәрне алуы.

Белешмәләрне файдалануның максаты гариза бирүче тапшырган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук, законнар һәм гариза бирүченең хокукларын бозуга юл куймый торган карар кабул итү.»;

3.10.1 пунктның беренче абзацында «Нәтиҗәне бирү» сүзләрен «Нәтиҗә» сүзе белән алыштырырга;

3.12.3 пунктның икенче абзацында «гариза регистрацияләнгәннән соң бер эш көне эчендә” сүзләрен «гариза кергән көнне» сүзләре белән алыштырырга;

3.12.4 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12.4. Бүлек белгече документларны карый да, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтүләр кертү максатыннан әлеге Регламентның

3.6, 3.9 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкиленә) имза куйдырып шәхсән үзенә төзәтелгән документны тапшыра, гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хата булган төп нөсхәне ала, яки гариза бирүче адресына почта аша (электрон почта аша) Министрлыкка техник хата булган документның төп нөсхәсен китереп документны алу мөмкинлеге турында хат юллый.»;

өченче абзацны «кертелгән үзгәрешләр белән» сүзләре белән тулыландырырга.